# Математика дәресе

**_Оештыру моменты._**

**_Тема_** **:** Өлеш.

**_Максат:_** 1.Өлешнең барлыкка килүе, аталышы һәм укылышы белән таныштыру.

2.Төрле төрдәге күнегүләр эшләү күнекмәләрен ныгыту.

3. Балаларның фикерләү сәләтәрен үстерү.

*Исәнләшү*

Хәерле көн телик таңнар саен,
Аяз күкләр телик җиребезгә.
Кояшлы көн телик һәр кешегә,
Һәм иминлек телик җиребезгә ,
Хәерле көн телик барчабызга,
Хәерле көн телик үзебезгә

# ***<u>Телдән исәпләү.</u>*** 1.

## ***Сүзләрне табу.***

49: 7 ә
7х2 н
24:8 р
6х3 и
21:3 ә
7х6 ф

42:7 у
7х8 р
28:4 а
9х4 л
24:8 с
9х6 д


| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | 42 | 7 | 3 | 18 | 14 |
| ә | ф | ә | р | и | н |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 54 | 6 | 3 | 36 | 7 | 56 |
| д | у | с | л | а | р |

# 2. Игътибарлылыкка күнегү.









# *3. Тест*

1) Китапта 56 бит. Камил һәр көнне 8 әр бит укыса, ул бу китапны ничә көндә укып бетергән?

ә) 8 көндә ү) 9 көндә ө) 7 көндә

2) Бер китапта 30 бит, ә икенчесендә 10 бит. Беренче китаптагы битләр икенче китаптагыга караганда ничә тапкыр артыграк?

л) 3 тапкыр м) 20 тапкыр н) 40 тапкыр

3) Турыпочмаклык формасындагы түтәлнең буе 4 м, ә киңлеге 2 м. Түтәлнең мәйданын тап.

д) 8 м е) 8 м ж) 6 м

4) Тегүче бер күлмәккә 6 төймә таккан. Шундый 4 күлмәккә ничә төймә кирәк булыр?

ч) 10 төймә ш) 24 төймә э) 22 төймә



## *Яңа тема өстендә эш.*

# Өлеш




*1. Сүзлек эше.*

**Өлеш –**
**нинди дә булса бер бөтеннең аерым кисәге.**

# 2. Практик эш.








$\frac{1}{3}$ $\frac{1}{6}$ $\frac{1}{4}$

$\frac{1}{8}$




$\frac{1}{5}$





$$\frac{1}{6}$$

$\frac{4}{6}$




$\frac{1}{6}$

$\frac{2}{6}$


$\frac{1}{6}$

# 3. Дәфтәрләрдә эш.

*Квадратларны төрле ысуллар белән 4 тигез өлешкә бүлү,1\4 өлешен табу.*




Фигураларның буялган өлешләрен атап чыгу.



# Дәрескә йомгак ясау.

*1. Фигураларның 1/8, 1/2,1/6,1/4, 1/3 өлешләрен табып билгеләгез.*



# *2. Өлешләрне чагыштырыгыз. (<, >, =)*

1/3 * 1/8 | 1/12 * 1/9 | 1/6 * 1/8

1/2 * 1/9 | 1/2 * 1/4 | 1/9 * 1/2

**Тигез өлешләр күбәйгән саен, аның күләме кечерәя бара.
Ләкин өлешләр тигез бүленергә тиеш.**

# ***Өй эше.***

*1.№ 7, бит 81;*

*2. зирәклеккә бирем, бит 81;*

*(теләк буенча)*